**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 февраль № 119

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре турында» 2012 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 22 июнь, 542 нче; 2013 ел, 4 июль, 477 нче; 2014 ел, 26 апрель, 270 нче; 2015 ел, 30 апрель, 301 нче; 2016 ел, 25 февраль, 115 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктта «2016 елда» сүзләрен «2016 һәм 2017 елларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү һәм бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртипләрен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 июль, 477 нче; 2014 ел, 26 апрель, 270 нче; 2015 ел, 30 апрель, 301 нче; 2016 ел, 25 февраль, 115 нче; 2016 ел, 26 май, 358 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү тәртибендә:

1 нче пунктта «2016 елда» сүзләрен «2016 һәм 2017 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

7 нче пунктта «утыз көн» сүзләрен «утыз эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибендә:

1 нче һәм 5 нче пунктларда «2016 елда» сүзләрен «2016 һәм 2017 елларда» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\119.doc